**ГЛАВА ШАПШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422708, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Шапши, ул.Ленина, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘПШИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Шәпши авылы, Ленин ур, 1

Тел./факс: +7(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» октябрь 2022 ел № 2

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге Уставының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22 маддәсе һәм 23.10.2009 ел, №163 карары (08.05.202020 ел, 09.10.202020 ел, №6 редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елның 21 октябрендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Кызыл Шәрыкъ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1.Иске һәм ашыгыч агачларны кисү;

2.Кызыл Шәрыкъ торак пункты эчендәге юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау

3. Кызыл Шәрыкъ авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» « КАРШЫ"»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы _____________ В. А. Беляков